Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 18**

Котлы Бөкәш авылы 2023 елның 19 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл
җирлеге Советы депутаты статусы турында
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл
җирлеге Советының 05.07.2023 №12 карары
белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Техник хатаны бетерү һәм муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 05.07.2023 №12 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

18 статьяның 1 пунктының б пунктчасын) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш, күчемсез милек милекчеләре ширкәте) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгының (Раиса) алдан хәбәр итүеннән;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы Г.Г. Нәҗипов